| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | | |
|---|---|---|
| **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**<br>**02.05.2024** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 1210** |

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 31 маендагы 412 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 31 октябрендәге 1377 номерлы карарын үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «Зеленодольск муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2022 елның 17 гыйнварындагы 45 номерлы карарына (Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 10 мартындагы 506 номерлы, 2022 елның 18 октябрендәге 2765 номерлы, 2023 елның 26 гыйнварындагы 105 номерлы номерлы, 2023 елның 30 июнендәге 1923 номерлы, 2023 елның 20 декабрендәге 4112 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. (1 нче кушымта) Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә:

VI бүлекнең 4 пунктындагы унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» мактау билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» мактау билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклау һәм үстерү өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе 2 процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» мактау билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» мактау билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклау һәм үстерү өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе өчен өстәмә акча Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.»;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтаның «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының (Совет Социалистик Республика Союзының, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының) стимуллаштыру характерындагы

түләүләр бирелә торган ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.20 – 1.26 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.20. | «Мактаулы остаз» күкрәк билгесе |
| 1.21. | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Ветеран» күкрәк билгесе |
| 1.22. | «Намуслы хезмәт һәм батырлык өчен» медале |
| 1.23. | «Мәгариф һәм фәнни-технологик үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга өлеш керткән өчен» медале |
| 1.24. | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Мактаулы хезмәткәр» исеме |
| 1.25. | «Яшь галим» күкрәк билгесе |
| 1.26. | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының Мактау грамотасы»; |

1.2. (2 нче кушымта) Зеленодольск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә:

V бүлекнең 4 пунктындагы унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» мактау билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» мактау билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклау һәм үстерү өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе 2 процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» мактау билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» мактау билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклау һәм үстерү өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе өчен өстәмә акча Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.»;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтаның «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының (Совет Социалистик Республика Союзының, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының) ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.20 – 1.26 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «1.20. | «Мактаулы остаз» күкрәк билгесе |
| 1.21. | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Ветеран» күкрәк билгесе |
| 1.22. | «Намуслы хезмәт һәм батырлык өчен» медале |
| 1.23. | «Мәгариф һәм фәнни-технологик үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга өлеш керткән өчен» медале |
| 1.24. | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Мактаулы хезмәткәр» исеме |

| | |
|---|---|
| 1.25. | «Яшь галим» күкрәк билгесе |
| 1.26. | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының Мактау грамотасы»; |

1.3. (3 нче кушымта) Зеленодольск муниципаль районының өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә:

VI бүлекнең 2.2 пунктындагы унберенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» мактау билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» мактау билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклау һәм үстерү өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе 2 процент тәшкил итә. «Мәгарифтәге казанышлар өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе, «Мактаулы остаз» мактау билгесе, «Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән өлкәсе отличнигы» мактау билгесе, «Телләрне, мәдәниятләрне, традицияләрне саклау һәм үстерү өчен» күкрәк билгесе, «Яшь мөгаллим» күкрәк билгесе өчен өстәмә акча Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры (Татарстан Республикасы мәгариф министры) боерыгы нигезендә билгеләнә.»;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтаның 1 нче таблицасындагы «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының (Совет Социалистик Республика Союзының, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының) ведомство (тармак) бүләкләре» бүлегенең 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 1.18 – 1.24 пунктчалар өстәргә:

| | |
|---|---|
| "1.18. | «Мактаулы остаз» күкрәк билгесе |
| 1.19. | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Ветеран» күкрәк билгесе |
| 1.20. | «Намуслы хезмәт һәм батырлык өчен» медале |
| 1.21. | «Мәгариф һәм фәнни-технологик үсеш өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруга өлеш керткән өчен» медале |
| 1.22. | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының «Мактаулы хезмәткәр» исеме |
| 1.23. | «Яшь галим» күкрәк билгесе |
| 1.24. | Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгының Мактау грамотасы»; |

2. Учреждение җитәкчеләренә үзләренең локаль актларын әлеге карарга туры китерергә.

3. Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасының (http://pravo.tatarstan.ru) хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) мәгълүмати сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче З.Ф.Хәбибуллин